**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Азбаба урта гомуми белем бирү мәктәбе**

<u>8нче сыйныфта</u>

<u>Татар теле дәресе</u>

# Дәреснең темасы:

**“Синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре”**

# Дәреснең максаты:

***Белем бирү максаты*** **: синтетик иярченле кушма җөмләләр турындагы белемнәрен тирәнәйтү,бу төр җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәсе бирү.**

***Үстерү максаты*****: укучыларның чагыштыру, анализ ясый белү,кагыйдәләр формалаштыра һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү,синтетик иярченле кушма җөмләләрдә тиешле тыныш билгеләрен куя белү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.**

***Тәрбия максаты*****: газиз аналарга мәхәббәт,игътибарлы мөнәсәбәт,шәфкатьлелек,хөрмәт,горурлану хисе тәрбияләү.**

# ТЕСТ





1.Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә ничек атала?

а)тезмә кушма җөмлә;

ә )иярченле кушма җөмлә;

б)теркәгечле тезмә кушма җөмлә.

2.Иярченле кушма җөмләләр төзелеше ягыннан түбәндәге төрләргә бүленәләр:



а)аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләр;

ә)иярчен ия,хәбәр,аергыч,тәмамлык,хәл җөмләләр;

б)бары тик синтетик кына була.

3. Иярченле кушма җөмләләр мәгънәләре буенча түбәндәге төрләргә бүленәләр:

а)иярчен ия һәм иярчен хәбәр;



ә)аналитик һәм синтетик;

б)иярчен ия,хәбәр,тәмамлык,аергыч,хәл,аныклагыч.

4. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә компонентларны бәйләүче чаралар:

а)иярчен җөмләнең хәбәре составында торалар;
ә)иярчен җөмләнең хәбәре составында тормыйлар;
б) баш җөмләдә киләләр.



5. Синтетик иярчен җөмләләр кайсы телләргә хас:

а)татар теленә һәм рус теленә;
ә) төрки телләргә,шул исәптән татар теленә дә;
б) рус теленә.

6.Синтетик бәйләүче чараларга керми:

а)килеш кушымчалары,фигыль формалары;

ә) бәйлек һәм бәйлек сүзләр;

б) мөнәсәбәтле сүзләр;

в)янәшә тору.

7.”Ана җиргә яңа тормыш алып килгәнгә,кешелек утын сүндермичә,буыннарны буыннарга тоташтырганга,без аналарга мәхәббәтле,игътибарлы,ихтирамлы булырга тиешбез”җөмләсенә кайсы схема туры килә:

а)(...-гәнгә),(...-ганга),[  ].

ә)(...-ганга),[  ].

б)(...-гәнгә),(...-мичә),(...-ганга),[  ].



# ТИКШЕР!!!

## ДӨРЕС ҖАВАПЛАР:

1-ә)

2-а)

3-б)

4-а)

5-ә)

6-б)

7-ә)

**Хатасыз эшкә-”5”ле**

**1 хатага-”4”ле**

**2-3 хатага-”3”ле билгесе куела.**

Ташлама,Әнкәй,ташлама
Мине изге доганнан.
**Ташласаң изге доганнан,**
**Мин бәхетле булалмам.**

# МӘКАЛЬЛӘР:

1)Ана-шәфкать диңгезе.

2)Ана- кояш җылысы.

3)Ата-анага ни күрсәтсәң,үзең дә шуны күрерсең.

4)Ана күңеле балада,

Бала күңеле далада.

5)Туган ана-бер,

Туган ил-бер.

6)Ана назын тоеп яшәү-зур бәхет ул.

**Җөмлә:**

**1.*Изге доганнан ташласаң,*мин бәхетле булалмам.**

## КАГЫЙДӘ:

**Үзе бәйләнгән сүздән ерак торган синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдән өтер белән аерыла.**

**Җөмлә:**

**<u>Мин тәрәзәләрне *саф һава керсен өчен* ачтым.</u>**

**КАГЫЙДӘ:**

**Үзе ияргән сүз белән янәшә торган синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдән бернинди билге белән дә аерылмый.**

# Җөмлә:

***Өеңә барсам***-эштән кайтмагансың,
***Эшеңә барсам***-әле син килмәгән.

## КАГЫЙДӘ:

**Әгәр дә иярчен шарт һәм кире җөмләләр баш җөмләдәге эш яки хәлгә контраст булган эшне белдереп килсәләр,баш җөмләдән сызык белән аерылалар .**

# Схема-нәтиҗә

а)Өтер куела:

(...-куш.),[...б.сүз].

(...-дип),[...б.сүз].

ә)Тыныш билгесе куелмый:

(   )[б.сүз ...].

б)Сызык куела(каршы тору):

(с.и.шарт,кире ж.)-[  ].

**Бирем: Җөмләләрне тикшерергә һәм тыныш билгесе куелышын аңлатырга.**

1.Ата-аналарыгыз аяк өстендә торганда,сез утырып тормагыз.

2.Алар бәрәңгене әнисе ачуланмаслык кадәр генә алдылар.

3.Әти-әниегез утырып торган вакытыгызда килсәләр,ачык йөз белән торып каршылагыз!

4.Ата-аналарыгыз сезгә нәрсә бирсәләр дә,һәрвакыт риза булыгыз.

5.Бу начар өйнең эчендә икмәге юк ярлы бар.

6.Ата-аналарыгыз һәрвакыт сезнең өчен тырышканга күрә,сез дә аларның бу яхшылыкларын камил кылып кайтарыгыз.

# Карточкалар белән эш.

**1нче вариант.**

**Җөмләләрне тыныш билгесе куелмаслык итеп үзгәртеп язарга.**

**1)Төн караңгы булса да,бәрәңге арасындагы сукмак күренә иде.**

**2)Сезнең якта көн дә кояш чыга,**
**Алсу йөзең кебек елмаеп.**

**3)Илчеләр килеп җитәр-җитмәс,ишекләр ачылды.**

**2нче вариант.**

**Җөмләләрне тыныш билгесе куелырлык итеп үзгәртеп язарга.**

**1)Күңелләрем сине язгы сулар ургып аккан чакта юксына.**

**2)Әнием,сирәк язасың дип үпкәлисең.**

**3)Басудагы һәр эшне агроном кушканча эшлибез.**

## Схемалар буенча җөмләләр төзергә

1. (...-гач),[    ].

2. [...(...-га күрә)...].

3. (    ) [  ].

# нәтиҗә:

а)Өтер куела:

(...-куш.),[...б.сүз]. 

(...-дип),[...б.сүз].

ә)Тыныш билгесе куелмый:




(  )[б.сүз ...].

(с.и.урын ж.)[  ].

(с.и.аергыч ж.)[  ].

(с.и.тәм.ж.)[  ].

б)Сызык куела(каршы тору):

(с.и.шарт,кире ж.)-[  ]. 

# ӨЙ ЭШЕ



1.52нче биттәге кагыйдә,55нче биттәге сораулар.

2.Төрле ситуацияләр язылган карточкалар буенча синтетик иярченле кушма җөмләләр уйлап язарга (ситуацияләр: «Сиңа көтелмәгән бүләк тапшырдылар…», «Син көчле яңгырга эләктең…», «Сине староста итеп сайладылар…», «Син кызыклы китап укыдың…», «Син бүген бик бәхетле…»).

# ДӘРЕС БЕТТЕ, ЧЫГАРГА МӨМКИН!!!

